РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ШЕМОРДАНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422050, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с. Шемордан, ул. Лермонтова, 2
тел. (84362) 2-27-05

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘМӘРДӘН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422050, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Шәмәрдән авылы Лермонтов урамы,
2 йорт
тел. (84362) 2-27-05

e-mail: Shmd.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

02.02.2026 — № 15-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан 2016нчы елның 20нче декабрендә 74 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы Нигезләмә”гә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016нчы елның 27нче сентябрендәге №668/пр боерыгы белән расланган “Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында“ 2017нче елның 19нчы июнендәге 892/пр номерлы боерыгын кабул итү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының 20.12.2016 №74 карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Шәмәрдән авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыннардан файдалану (наемга алу өчен түләү күләмен исәпләү) тәртибе турындагы Нигезләмә”гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2. пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урынынннан файдаланган өчен түләү (наем әчен түләү) билгеләнгән вакытка - 0,2 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндүге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:

- өч һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен – 0,1;

- иминият пенсияләрен алучылар өчен (“Иминият пенсияләре турында”гы 28.12.2013 елның №400-ФЗ Федераль законы нигезендә) – 0,1».

1.2. 4.1. пунктнын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Торак урынны наемга алган өчен түләү күләме торак урынның сыйфатын һәм төзеклеген, йортның урнашу урынын характерлый торган коэффициенттан файдаланып билгеләнә:

| Коэффициентлар | Куллану үзлекләре | Коэффициентның кыйммәте |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урынның сыйфат күрсәткечләре (К1) | Стеналар материалы:<br>кирпеч, таш, монолит;<br><br>эре панельле, блоклы;<br><br>агачтан, катнаш | <br>1,2<br><br>1,0<br><br>0,8 |
| Төзекләндерү күрсәткечләре (К2) | Төзекләндерелгән торак йортлар (үзәкләштерелгән салкын су белән тәэмин ителгән һәм су агызу системалы);<br>Төзекләндерелгән торак йортлар (үзәкләштерелгән салкын су системасы белән тәэмин ителгән);<br>Төзекләндерелмәгән торак йортлар | 1,2<br><br>1,0<br><br>0,8 |
| Урын күрсәткечләре (К3) | Җирлекнең административ үзәге;<br>Җирлекнең башка торак пунктлары | 1,2<br>0,8 |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә

3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең рәсми стендларында бастырып чыгарырга.

Шәмәрдән авыл җирлеге башлыгы: А.К.Валиев